**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 8 апрелендәге 1034 номерлы карары**

## Хач йөреше белән Пасха бәйрәме гыйбадәтен уздыру чорында Челюскин урамы буенча транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләү турында

Хач йөреше белән Пасха бәйрәме гыйбадәтен уздыру чорында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатыннан, Җирле дини оешма – Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе карамагындагы Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Изге гадел Иоанн Кронштадтский храмы православие приходы мөрәҗәгатен исәпкә алып, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. кирәк булганда 2025 елның 19 апрелендә 23.50 сәгатьтән 2025 елның 20 апрелендә 00.20 сәгатькә кадәр Челюскин урамы буенча, Тар Урамнан Побежимов урамына кадәрге участокта, транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләүне кертергә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе (Р.Х.Шәмсетдинов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябуны оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участогында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН